Фикер

Йосыф ДӘҮЛӘТШИН
Шәһри Казан

# ОЯЛМАСАҢ, ни теләсәң шуны эшлә

Җир өстендә тормыш иткән халыклар һәм өммәтләр үзләренең яхшы тәрбияләре вә күркәм әхлаклары белән тәзек булырлар, гүзәл холыклары белән олуг дәрәҗәләр табарлар, биек үрләрне яуларлар... Кешенең тышкы яктан үз-үзен тотышы, әдәп-әхлагы - эчендә булган иманының чагылышы, көзгеседер. Динебездә булган һәр канун кешенең әхлагын саклый, камилләштерә. Пәйгамбәребез (с.г.в.)нең дә төп вазифаларының берсе кешеләрнең күркәм әхлакларын камилләштерү булды.

Динебездә әхлак ишекләре күптөрле һәм киндер. Әмма ул ишекләрне ачып керергә уйласаң, иң элек аларның ачкычын табарга кирәк. Шиксез, күркәм холык ишекләренең ачкычы бар һәм безгә таныштыр. Ул ачкыч хакында без кечкенәдән әниләребездән, әбиләребездән ишетеп беләбез. Халкыбызга күп еллар динсезлек чорында яшәргә туры килсә дә, бу сыйфат онытылмады. Әйе, бу һәрберебезгә таныш - оялу сыйфаты. Оят үлчәве белән кешенең әхлагы үлчәнер, изгелеге һәм бозыклыгының күләме беленер.

Кешедә булган изгелекнең дә, явызлыкның да галәмәте бар. Изгелекнең галәмәте: йомшаклык, ояла белү һәм киң күңеллелектер. Явызлыкның күрсәткече: оятсызлык, азгынлык һәм әшәкелектер. Әгәр бер кешенең йөзендә хәерсез эштән оялу, читенсену күрсәң, димәк, бу кешедә өмет бар. Аның эчендә хәерлелек нуры бетмәгән. Кайвакыт мәчеткә баш-аяк гөнаһка чумган кешеләр килә. Алар белән сөйләшә башлагач, кайберләре оятларыннан күзләрен аска төшерә. Гадәттә, андыйларны үгетләү нәтиҗә бирә. Ләкин борынын чөеп гөнаһлары белән масаеп утыручыны төзәтергә маташу артык файда бирми. Кеше тормышта ничек кенә ялгышса да, күңелендә оялу хисләре бетмәсә, аның төзәлүе өметле, иншә Аллаһ.

Нәрсә соң ул оят? Ул нәрсәдә чагыла? Оялу - кешене изгелеккә этәреп, яманлыктан туктата торган Аллаһы Тәгаләдән салынган сыйфаттыр. "Өстенә оят киемен кигән кешенең гаебен күрмәсләр", - дигәннәр борынгылар.

## ОЯЛ, ИМАН ИЯСЕ!

Җир йөзенә килгән һәр пәйгамбәр кешелекне ояла белергә чакырды. Пәйгамбәребез (с.г.в.) "Кешеләргә әүвәлге пәйгамбәрләрдән ирешкән сүзләрнең берсе - оялмасаң, ни теләсәң шуны эшлә", - диде. Оялу кешенең йөрәгендә булган иманының бер күрсәткече булып тора.

Җир өстенә иңгән һәр шәригатьнең үзенә хас үзенчәлекләре булды. Пәйгамбәребез: "һәр диннең үз әхлагы булды, исламның әхлагы - оялу", - диде. Димәк, җир өстендә нәкъ ислам, Коръән әһеле оялуның үрнәге булырга тиеш. Әгәр кешелектә мөселман һәм мөслимәләр оятларын югалтсалар, башкалардан сыйфатны ничек өмет итәргә була? Пәйгамбәрнең бу сүзләре өстебезгә зур җаваплылык өсти, безне оят мәсьәләсендә аеруча җитди булырга чакыра.

Сөекле Пәйгамбәребез безне һәрвакыт ояла белергә өйрәтте, үзе дә бик ояла иде. Бервакыт, Пәйгамбәребез бер сәхабәсе янынан үтеп барганда, аның үз энесен артык оялганы өчен шелтәләгәнен күрде һәм: "Аны шелтәләмә, чөнки оялу - иманның бер билгесе", - диде. Кемнәрдер: "Бүген заманасы башка шул, оятың булса, акча үләрсең, өстеңнән таптап китәрләр", - диләр. Кеше исемен йөртүче зат кай чорларда гына яшәмәсен, тәкъдир җилләре аны кайларга гына ташламасын, оялу һәрвакыт зиннәт - матурлык булып кала. Пәйгамбәребез: "Оялу хәерлелектән башка нәрсә белән килмәс", - диде. Бөтен дөньясы оятын югалтса да, иман иясе бу изге сыйфатны сакларга, яшәтергә, киләсе буыннарга тапшырырга тиеш.

Кайберәүләр оялчанлыкны кешенең көчсезлеге - гаҗизлеге итеп күрә. Андыйлар бу мактаулы сыйфатның чын мәгънәсен аңлап бетерми. Адәмнәргә Аллаһыдан бирелгән "оялу" сыйфаты хәерле эшләргә киртә булырга тиеш түгел. Әгәр кеше оялу сәбәпле хак сүзен әйтмәсә, "Мин оялам", дип башкаларны изгелеккә өндәмәсә, явызлыктан тыймаса, оялу сәбәпле гыйлем алмаса, бу оялу түгел, бәлки зәгыйфьлек һәм куркаклыктыр. Аллаһының илчесе өеннән чыкмаган яшь кыздан да оялчанрак булды, әмма ул кешеләрдә берәр төрле гаделсезлеке күрсә, аның ачуы йөзенә чыга иде. Бервакыт аның янына кеше әйберен урлаучы бер хатынны китерәләр. Арадан берәү, ул хатынның бик дәрәҗәле нәселдән булуын искә төшереп, аны якламакчы була. Пәйгамбәребез аңа, ачу белән: "Син Аллаһ куйган чикләрдә кемгәдер шәфәгать кылмакчы буласыңмы? Вәллаһи, яраткан кызым Фатыйма урласа, аның да кулын кистерәм", - дип әйтә.

## АЛЛАҺЫДАН ОЯЛУ

Ояты булган үзенең ата-анасыннан, баласыннан, башкалардан ояла... Ләкин Адәм баласы иң әлек үзен юктан бар итүче Раббысыннан оялырга тиеш. Моның өчен кеше Раббысыннан аңа булган чиксез нигъмәтләрен күрә белергә, шул нигъмәтләрдә яшәп тә, үзенең тиешле дәрәҗәдә Аңа рәхмәтле булмавын, күпме гөнаһ-хаталар кылуын аңларга тиеш. Күпләребез җиңел генә: "Без Аллаһыдан оялабыз", - диләр. Әмма Раббыннан оялуның үз шартлары бар.

Аллаһыдан оялу Аның әмерләренә буйсынып тыйган хәрамнарыннан сакланып кына гамәлгә аша. Пәйгамбәребез (с.г.в.) "Аллаһыдан чын оялу белән оялыгыз", - диде. Кешеләр аңа: "Без Аллаһыдан оялабыз, әлхәмдүлилләһ!" - диделәр. Ул: "Юк, мин андый оялуны әйтмим. Бәлки, Аллаһыдан чын оялу белән оялучы үзенең башын һәм башында булганын гөнаһтан сакласын. Карынын һәм анда булганын хәрамнан сакласын. Үлемне һәрчак истә тотсын. Ахирәткә омтылучы дөнья зиннәтен артка куйсын. Шушы нәрсәләрне үтәүче генә Аллаһтан чын оялучы булыр".

Димәк, Аллаһтан оялучы үзенең башын яман уйлардан, мәкерле планнардан сакларга тиеш. Башында булган күзләрен, колакларын, телен гөнаһлы эшләрдән саклап кына оялучы булырга мөмкин. "Карынын һәм анда булганын хәрамнан сакласын", - дигән сүзләргә кешенең хәрам ризыклардан, эчемлекләрдән саклануы, зинадан ерак торуы керә. Шушы шартларны үтәп кенә, Аллаһыдан хак оялу белән оялып була.

Без, гадәттә, берәр нәрсә эшләр алдыннан "Кеше нәрсә әйтер?", "Башкалар күзенә ничек карармын?" кебек сүзләрне кабатлыйбыз. Кешеләрдән оялабыз кебек тә, ә Аллаһыдан кем оялыр? Пәйгамбәребез үзенең бер сәхабәсенә: "Үз халкыңнан булган бер изге кешедән оялган кебек, Аллаһыдан да шулай оял", - диде. Чыннан да, Күп кенә кимчелекле эшләребездән безнең өчен зур хөрмәткә ия булган кеше каршында тыелыр идек. Кызган баштан хатынга "тутырып" әйтим әле дигәндә, өеңә газиз анаң килеп керсә, әйтәсе сүзләрең чыгармы? Әтиебездән оялабыз. Әмма ник, Раббыбыздан оялмыйбыз? Ул һәр вакыт безнең белән, безне күрә һәм ишетә.

## ОЯЛУНЫҢ ҮРНӘКЛӘРЕ...

Газиз кардәшләрем, Аллаһыдан оялыйк. Оялуның үрнәге булган сәхабәләр һәрвакыт Аллаһының карашын тоеп, Аннан оялып яшәделәр. Бер сәхабә Пәйгамбәребездән гаурәт хакында сорашкач, ул аңа: "Гаурәтеңне хатыныңнан башкалардан яшер", - диде. Сәхабәсе: "Ялгызың калганда нишләргә?" - дип сорагач, Аллаһының илчесе аңа: "Аллаһы синең оятыңа кешеләргә караганда лаеклырактыр", - диде. Сөекле пәйгамбәребез (с.г.в.) VII гасырда сахрада яшәүче кешене, өйдә ялгызың калганда да анадан тума йөрергә оял, дип өйрәтте. Бүген исә дистәләрчә ирләр һәм хатыннар ялангач хәлдә мунчалар керәләр. Ярый безнең илдә ирләр белән хатыннар аерым бүлмәләргә җыела. Күп кенә "алга киткән" Европа илләрендә мунчаларда ирләр хатыннар белән бергә юыналар, диләр.

Кайчандыр кешенең никадәр оялчан булуларын күреп гаҗәпләнәсең. Әбү Бәкер хаҗәтен үтәгәндә, оятыннан, киеме белән йөзен каплаган. Госман ибн Гаффән госел алганда, Аллаһыдан оялып, тураймаган, бөкләнеп юына торган булган. Ибн Габбас юынганда, гаурәт урыннарына юка чүпрәк япкан.

Бүген оялу сыйфаты чыннан да модадан чыгып бара, ахры. Кайчандыр, иманлы кешеләр өчен кеше алдында йомыш үтәү кыргыйлык саналса, бүген "двухсотый" "Lahg Cruiser" дан төшеп, юл кырында сөйләшә-сөйләшә йомыш үтәп торучы "затлы" егетләрне еш күрергә була. Кайчандыр әти-әнигә күз күтәреп карау оят эш булса, хәзер аларга күз, сүз түгел, кул да күтәрелә. Мәктәптә укыганда әти-әни эштән кайтып керсә, без тизрәк магнитофонны сүндерә идек. Алар каршында музыка тыңлап утыру ничектер оялдыра иде. Хәзер балаларына "мишәйт итмим" дип, әти-әни өйдә аяк очында йөри. Әти бүлмәгә килеп керсә, диванда сузылып яту оят иде. Хәзер кайберәүләр әти-әнисенең бүлмәгә керүләрен дә, чыгуларын да күрмиләр...

Кешелек оялу сыйфатын югалткан саен, җир өстендә гөнаһ кылу, азгынлык, явызлык тамыр җәя. Бервакыт Хөсәен ибн Гали янына бер кеше килә һәм: "Мин гөнаһ кылудан сабыр итә алмыйм, мине вәгазьлә әле", - дип үтенә. Хөсәен аңа: "Биш нәрсәне эшлә дә ни теләсәң, шуны кыл. Әгәр бик каты гөнаһ кылырга теләсәң, Аллаһының сиңа булган ризыгыннан баш тарт. Ашама, эчмә, шуннан соң ни теләсәң, шуны эшлә", - ди.

- Нәрсә ашыйм соң? Бөтенесе дә Аның ризыгы бит, - дип гаҗәпләнә теге кеше.

- Гөнаһ кылыр алдыннан Аллаһының җиреннән башка җиргә кит, анда исә ни теләсәң, шуны эшлә, - ди Хөсәен.

- Аллаһының җиреннән ничек чыгарга соң? Барысы да Аның җире бит.

- Аллаһ сине күрми торган аулак урын тап та, шул урында нинди гөнаһ теләсәң, шуны кыл.

- Аллаһ күрми торган урын юк бит!

- Беркөнне үлем фәрештәсе каршыңа килеп басар, син аны кире борып җибәр, аннан ни теләсәң, шуны кыл.

- Ул мине тыңлап тормас шул.

- Кыямәттә фәрештәләр сине утка кертkәндә, син кермә. Менә шул вакыт ни теләсәң, шуны эшлә.

- Булды, җитте. Бу көннән соң Раббым мине һичвакыт бозыклыкта күрмәс.

Чыннан да, Хөсәеннең бу сүзләрендә фикерле белүчеләр өчен гыйбрәт бар. Күп вакытта без яман эшләребезне кылганда, үзебезнең Кем җирендә йөргәнебезне, Кем биргән ризыклардан ашавыбызны, Кемнең сулары эчүебезне, Кемнең һаваларын сулавыбызны онытып җибәрәбез. Кемнең кояшы астында яшибез? Кем биргән күзләр белән күрәбез, колаклар белән ишетәбез, аяк-куллар белән кулланабыз? Бу сорауларны туктаусыз бирергә була, әмма җавабын кем бирә? Чыннан да, оятын югалткан кеше генә җир өстендә бозыклык кыла.

Аллаһының җирендә кеше рәнҗетеп, явызлык кылып яшәүче Аллаһыдан оялмый.

Аллаһының безгә күпме хәләл ризыклары булып та, үзенә һәм гаиләсенә хәрам ашатучы Аллаһыдан оялмый.

Аллаһы безләргә хәләл никах, гаилә тормышы биреп тә, зина юлында йөрүче Аллаһыдан оялмый.

Кардәшләрем! Оялыйк, безне кайгыртып торучы Раббыбыздан, безне үстергән газиз ата-анабыздан. Оялыйк безгә якын булган луслардан, безне яратучы гаилә әһелләребездән. Оялыйк безгә аң-белем бирүче остазларыбыздан, безгә хөрмәт күрсәтүче шәкертләребездән. Оялыйк чал чәч иясе булган өлкән буыныбыздан, бездән үрнәк алучы яшьләребездән. Оялыйк үз-үзебездән...

## Өфөлә намаҙ ваҡыты

**Сәфәр-Рабиғүл әүүәл 2013 миләди йыл**
**1434 һижри йыл.**

| Сәфәр, Рабиғүл әүүәл | Аҙна көндәре | Декабрь, Ғинуар | Иртәнге намаҙ | Ҡояш сыға | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. | Йәстү намаҙы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 13 | Дүшәмбе | 16 | 9.06 | 10.36 | 14.30 | 16.16 | 17.46 | 19.16 |
| 14 | Шишәмбе | 17 | 9.07 | 10.37 | 14.30 | 16.16 | 17.46 | 19.16 |
| 15 | Шаршамбы | 18 | 9.08 | 10.38 | 14.30 | 16.17 | 17.47 | 19.17 |
| 16 | Кесе йома | 19 | 9.09 | 10.39 | 14.30 | 16.17 | 17.47 | 19.17 |
| 17 | Йома | 20 | 9.09 | 10.39 | 14.30 | 16.17 | 17.47 | 19.17 |
| 18 | Шәмбе | 21 | 9.10 | 10.40 | 14.30 | 16.18 | 17.48 | 19.18 |
| 19 | Йәкшәмбе | 22 | 9.10 | 10.40 | 14.30 | 16.18 | 17.48 | 19.18 |
| 20 | Дүшәмбе | 23 | 9.11 | 10.41 | 14.30 | 16.19 | 17.49 | 19.19 |
| 21 | Шишәмбе | 24 | 9.11 | 10.41 | 14.30 | 16.20 | 17.50 | 19.20 |
| 22 | Шаршамбы | 25 | 9.12 | 10.42 | 14.30 | 16.20 | 17.50 | 19.20 |
| 23 | Кесе йома | 26 | 9.12 | 10.42 | 14.30 | 16.21 | 17.51 | 19.21 |
| 24 | Йома | 27 | 9.12 | 10.42 | 14.30 | 16.22 | 17.52 | 19.22 |
| 25 | Шәмбе | 28 | 9.12 | 10.42 | 14.30 | 16.23 | 17.53 | 19.23 |
| 26 | Йәкшәмбе | 29 | 9.12 | 10.42 | 14.30 | 16.24 | 17.54 | 19.24 |
| 27 | Дүшәмбе | 30 | 9.12 | 10.42 | 14.30 | 16.25 | 17.55 | 19.25 |
| 28 | Шишәмбе | 31 | 9.12 | 10.42 | 14.30 | 16.26 | 17.56 | 19.26 |
| 29 | Шаршамбы | 1 | 9.12 | 10.42 | 14.30 | 16.27 | 17.57 | 19.27 |
| 1 | Кесе йома | 2 | 9.12 | 10.42 | 14.30 | 16.28 | 17.58 | 19.28 |
| 2 | Йома | 3 | 9.11 | 10.41 | 14.30 | 16.29 | 17.59 | 19.29 |
| 3 | Шәмбе | 4 | 9.11 | 10.41 | 14.30 | 16.31 | 18.01 | 19.31 |
| 4 | Йәкшәмбе | 5 | 9.10 | 10.40 | 14.30 | 16.32 | 18.02 | 19.32 |
| 5 | Дүшәмбе | 6 | 9.10 | 10.40 | 14.30 | 16.33 | 18.03 | 19.33 |
| 6 | Шишәмбе | 7 | 9.09 | 10.39 | 14.30 | 16.35 | 18.05 | 19.35 |
| 7 | Шаршамбы | 8 | 9.09 | 10.39 | 14.30 | 16.36 | 18.06 | 19.36 |
| 8 | Кесе йома | 9 | 9.08 | 10.38 | 14.30 | 16.38 | 18.08 | 19.38 |
| 9 | Йома | 10 | 9.07 | 10.37 | 14.30 | 16.39 | 18.09 | 19.39 |
| 10 | Шәмбе | 11 | 9.07 | 10.37 | 14.30 | 16.41 | 18.11 | 19.41 |
| 11 | Йәкшәмбе | 12 | 9.06 | 10.36 | 14.30 | 16.43 | 18.13 | 19.43 |
| 12 | Дүшәмбе | 13 | 9.05 | 10.35 | 14.30 | 16.44 | 18.14 | 19.44 |
| 13 | Шишәмбе | 14 | 9.04 | 10.34 | 14.30 | 16.46 | 18.16 | 19.46 |
| 14 | Шаршамбы | 15 | 9.03 | 10.33 | 14.30 | 16.48 | 18.18 | 19.48 |